РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

12 ноябрь 2021 ел Буа шәһәре № 6-20

Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы нигезендә түләүсез җир кишәрлекләре алу хокукына ия булган гражданнар исемлекләрен әзерләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Җир кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2012 елның 11 февралендәге 6-16 номерлы «Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы нигезендә түләүсез җир кишәрлекләре алу хокукына ия булган гражданнар исемлекләрен әзерләү тәртибе турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы нигезендә түләүсез җир кишәрлекләре алу хокукына ия булган гражданнар исемлекләрен әзерләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 1 бүлек:

3 пунктта «дача төзелеше» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 2 бүлек:

17 пунктта «дача төзелеше» сүзләрен төшереп калдырырга;

18 пунктта «дача төзелеше» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Буа муниципаль районы
Башлыгы, Совет рәисе Р.Р. Камартдинов